РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

02.11.2021 ел №70

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Чирмешән муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендә булган муниципаль милек исемлегенә кертелгән, өченче затлар хокукларыннан (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәтне арендага бирү тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2019 елның 18 июлендәге 240 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 1 һәм 2 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 8 июнендәге 169-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, ярдәм алучы кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрын формалаштыру максатларында, шәхси эшмәкәрләр булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга (үзмәшгуль гражданнар) ярдәм чаралары күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2019 елның 18 июлендәге 239 номерлы карарына 1 нче кушымта белән расланган Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге

милкендә булган муниципаль милек исемлегенә кертелгән, өченче затлар хокукларыннан (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәтне арендага бирү тәртибенә тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Тәртипкә түбәндәге эчтәлекле 1.5 пункты өстәргә: «1.5. Исемлеккә кертелгән мөлкәт арендаторлары булып, шулай ук шәхси эшмәкәрләр булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затлар тора ала.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту район Советының икътисади сәясәт һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләнә.

Муниципаль район башлыгы,
Совет рәисе Ф.М. Дәүләтшин